| Республика Татарстан<br>Зеленодольский<br>муниципальный район<br>Исполнительный комитет<br>Нижневязовского городского<br>поселения | Татарстан Республикасы<br>Зеленодольск<br>муниципаль районы<br>Карамалы Тау шәһәр<br>җирлеге башкарма<br>комитеты |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **Карамалы Тау** **КАРАР**

**12.02.2019** **№13**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнары составында Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге Башкарма комитетының Резерв фонды турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында» Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советының 2014 елның 3 февралендәге 31 номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану сәбәпле, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнары составында Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитетының Резерв фонды акчаларын булдыру, тоту тәртибен,алардан файдаланунының хисаплылыгын билгеләү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнары составында Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге Башкарма комитетының Резерв фонды турындагы нигезләмәне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче А. М. Гыйниятов

Зеленодольск муниципаль районы
Карамалы Тау шәһәр җирлеге
Башкарма комитетының 2019 елның
12 февралендәге 13 номерлы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнары составында Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге Башкарма комитетының Резерв фонды турындагы нигезләмә**

1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнары составында Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге Башкарма комитетының Резерв фонды турындагы нигезләмә
Әлеге Нигезләмә белән Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге Башкарма комитетының Резерв фонды (алга таба - резерв фонды) акчаларын Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең көтелмәгән чыгымнарын финанслауга формалаштыру һәм тоту тәртибе билгеләнә.

1.2. Резерв фонды акчалары җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә бәйле тиешле финанс елына бюджетның чыгым өлешендә каралмаган көтелмәгән чыгымнарны финанслау өчен билгеләнгән.

2. Резерв фондын формалаштыру тәртибе

2.1. Резерв фонды Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнары составында төзелә.

2.2. Резерв фонды күләме Зеленодольск муниципаль районының Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советы карары белән Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджетын раслаганда билгеләнә һәм Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының расланган гомуми күләменең өч процентыннан артмаска тиеш.

2.3. Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең резерв фондыннан акча бүлеп бирү турындагы карарлары көтелмәгән чыгымнар барлыкка килгән очракларда кабул ителә.

3. Резерв фонды акчаларын тоту юнәлеше

– Резерв фонды акчалары түбәндәгеләрне финанслануга тотыла:
– көтелмәгән чыгымнарны, шул исәптән агымдагы финанс елында булган җирле дәрәҗәдәге гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла – казалардан килгән зыяннарны бетерү буенча авария-торгызу эшләрен үткәрүгә генә тотылган;
– социаль әһәмияттәге объектларда кичектергесез ремонт һәм торгызу эшләрен;
– иҗтимагый оешмаларга һәм мәдәният берләшмәләренә, поселок әһәмиятендәге чараларга ярдәм итүне;
– поселок әһәмиятендәге очрашулар, симпозиумнар, күргәзмәләр һәм семинарлар үткәрүне;
– гражданнарга бер мәртәбә премия түләүне һәм бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтүне, шул исәптән табигый бәла-казалардан һәм янгыннардан зыян күргән очракта да;
– гуманитар ярдәм күрсәтүне;
– Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карарлары буенча үткәрелә торган башка чараларны финанслауга.

Резерв фонды акчалары гадәттән тыш хәлләрне бетерү чараларын финанслауга һәм бары тик җирле дәрәҗәдәге табигый бәла-казалардан һәм янгыннардан зыян алганда бер тапкыр матди ярдәм күрсәтүгә генә бүлеп бирелә.

4. Резерв фондыннан акча бүлеп бирү тәртибе

4.1. Резерв фондыннан акча бүлеп бирү Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, учреждениеләр, оешмалар, предприятиеләр һәм физик затлар мөрәҗәгатьләре нигезендә, исәп - хисап һәм нигезләү кушымталары белән, кирәк булган очракта – Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе адресына җибәрелгән экспертларның, комиссияләрнең һәм башкаларның бәяләмәләре нигезендә башкарыла.

4.2. Карамалы Тау шәһәр җирлеге Башкарма комитетының исәп һәм хисап бүлеге тәкъдим ителгән документлар нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә алучы турында белешмәне, бүлеп бирелә торган акчаның күләме һәм аларны максатчан тоту яки акча бүлеп бирүнең максатка туры килмәве турында бәяләмәне үз эченә алырга тиешле күрсәтмә проектын әзерләп җибәрә.

4.3. Резерв фондыннан акча бүлеп бирү турындагы карар Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге Башкарма комитеты

җитәкчесе карары белән рәсмиләштерелә. Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән каралмаган максатларда акча тотуга юл куелмый.

4.4. Табигый бәла-казалардан һәм янгыннардан зыян күргән очракта, бер тапкыр матди ярдәм түләү табигый бәла-казалар һәм янгын аркасында зыян күргән һәм милкендә башка торак булмаган, башка торак бинадан файдаланмаган гражданнарга (торак урыннар милекчеләренә, ялланучыларга) бирелә.

4.5. Табигый бәла-казалардан һәм янгыннардан зыян күргән очракта бер тапкыр матди ярдәм күләме Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләмен тәшкил итә.

## 5. Резерв фонды акчаларын тоту турында хисаплылык һәм аннан файдалануны контрольдә тоту

5.1. Зеленодольск муниципаль районы Түбән Карамалы Тау шәһәр җирлеге Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Резерв фондының акчалары бүлеп бирелә торган учреждениеләр, оешмалар һәм предприятиеләр, хисаптан соң килүче айның 5 числосына кадәр, тиешле чаралар үткәргәннән соң, Карамалы Тау шәһәр җирлеге Башкарма комитетының исәп һәм хисап бүлегенә бүлеп бирелгән акчалардан максатчан файдалану турында мәгълүмат бирәләр.

5.2. Резерв фонды акчаларыннан максатсыз файдаланган очракта алар Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджетына бәхәссез тәртиптә алынырга тиеш.

5.3. Резерв фонды акчалары исәбеннән бүлеп бирелгән чыгымнар Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджетын үтәү буенча хисапларда бюджет классификациясенең тиешле бүлекләре һәм статьялары буенча чагылдырыла.

5.4. Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитеты квартал саен Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советына Резерв Фондының акчаларын тоту турында мәгълүмат бирә.

5.5. Резерв фондыннан бүлеп бирелгән акчаларның максатчан кулланылышын Зеленодольск муниципаль районының Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советы һәм “Зеленодольск муниципаль районының Контроль-хисап палатасы” муниципаль учреждениесе контрольдә тота.